КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 июль г.Казань № 541

«Математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү» грантын гамәлгә куярга.

2. Бу карарга теркәлгән «Математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 3 июль, 541 нче
карары белән расланды

«Математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында
нигезләмә

1. Бу Нигезләмә түбәндәгеләрне билгели:

«Математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү» грантын алу өчен конкурс нигезендә сайлап алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен (алга таба – грант, конкурс нигезендә сайлап алу);

грант бирү тәртибен.

2. Субсидияләр рәвешендә грант бирү тиешле финанс елына бюджет турындагы законда каралган бюджет ассигнованиеләре һәм грантлар бирү өчен Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Грант алучы – Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыручы, конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче дип танылган мәгариф оешмасы.

4. Грант бирү максаты – интернатта белем алучылар яшәү өчен шартлар тудырылган, математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларына булышлык күрсәтү.

5. Грант конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә. Конкурс нигезендә сайлап алу турындагы нигезләмә Министрлык боерыгы белән раслана.

6. Конкурста катнашучыларга карата таләпләр:

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия һәм төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча дәүләт аккредитациясе турында таныклык булу;

бер үк вакытта белем бирү оешмасында яшәп, математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын үзләштерүче белем алучылар өчен интернат булу.

Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары:

математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеге күрсәткечләре;

белем алучыларның аерым предметлар буенча бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадаларында, башка интеллектуаль конкурсларда һәм төрле дәрәҗәдәге ярышларда катнашу нәтиҗәлелеге;

математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын гамәли тормышка ашыру нәтиҗәләренә фараз.

Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары күрсәткечләренең мәгънәләре Министрлык тарафыннан билгеләнә.

7. Грант акчасы түбәндәгеләргә җибәрелә:

математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә;

математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын тормышка ашырганда мәгариф оешмаларының педагогик коллективын һөнәри үстерүгә һәм квалификациясен күтәрүгә;

белем алучыларның интеллектуаль конкурсларда һәм бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге ярышларда катнашуы нәтиҗәләре буенча педагогик коллективны матди бүләкләүгә.

8. Грантның максатчан билгеләнеше бар һәм ул грант алучы тарафыннан бу Нигезләмә белән күздә тотылмаган максатларда файдаланыла алмый.

9. Грант алу өчен конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче дип танылган мәгариф оешмасы грантының күләме 150 221,9 мең сум тәшкил итә.

10. Грант конкурс нигезендә сайлап алуга йомгаклар ясалган көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә Министрлык һәм конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче арасында төзелгән грант бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә. Килешү формасы Министрлык тарафыннан раслана.

Килешүдә түбәндәге нигезләмәләр карала:

грантның максатчан билгеләнеше;

грантны файдалану юнәлешләре;

грант күләме, грантны күчерү вакытлары;

грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисапны, шулай ук грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турындагы хисапны Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча кертү тәртибе һәм вакытлары;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан грант алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен саклавына тикшерүләр үткәрүгә ризалык;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча грант бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланган очракта, грантны кире кайтару тәртибе, шулай ук хисап финанс елында грантның файдаланылмый калган өлешен кире кайтару тәртибе;

килешү кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык.

11. Грант нәтиҗәлелеге күрсәткечләре:

математика, табигый-фәнни һәм мәгълүмати-технологик юнәлешләрдәге предметлар тирәнтен өйрәнелә һәм төп гомуми, урта гомуми белем бирә торган мәгариф программаларын үзләштерүче белем алучылар санын саклап калу;

аерым предметлар буенча бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадаларында, башка интеллектуаль конкурсларда һәм төрле дәрәҗәдәге ярышларда җиңгән һәм приз алган белем алучыларның өлешен арттыру;

төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буенча югары нәтиҗәләре булган белем алучыларның өлешен арттыру.

12. Грант конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләргә килешү белән билгеләнгән вакытларда күчерелә:

мәгариф оешмасына (гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмаларыннан һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларыннан тыш) – кредит оешмаларында ачылган хисап исәпләренә;

гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт мәгариф оешмасына – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән билгеләнгә тәртиптә.

13. Грант алучы Министрлыкка финанслар белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисапны, шулай ук грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турындагы хисапны килешүдә билгеләнгән формалар һәм вакытлар нигезендә тапшыра.

14. Бирелгән грант Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тотуның вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча бу Нигезләмә белән аны бирү буенча билгеләнгән максатлар һәм шартлар бозылу фактлары ачыкланган очракта, шулай ук грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре үтәлмәгән очракта, Министрлыкның тиешле таләпләрен алган көннән 60 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

15. Хисап финанс елында грантның файдаланылмаган өлеше грант алучы тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә килешүдә билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

16. Бу Нигезләмәнең 14 нче һәм 15 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемнә ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә Министрлык тарафыннан түләттерелергә тиеш.

17. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары законнар нигезендә грант алучылар тарафыннан шартлар, максатлар һәм грантлар бирү тәртибенең үтәлешен тикшерә.

18. Грантны максатчан һәм нәтиҗәле үзләштергән өчен, шулай ук конкурс нигезендә сайлап алуга тәкъдим ителгән документларның дөреслеге өчен җаваплылык грант алучыга законнар нигезендә йөкләнә.

19. Бюджет акчасын максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.